РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ

422750, село Большая Атня,
улица Советская, дом 38

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422750, Олы Әтнә авылы,
Совет урамы,38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

07.04. 2021ел № 87

Чернобыль АЭСындагы һәлакәт, "Маяк" җитештерү берләшмәсендәге авария аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарга һәм аларга тиңләштерелгән торак урыннарына мохтаҗ аерым категорияләрдәге затларга исәпкә кую һәм Дәүләт торак сертификатын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында.

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында "Федераль законның 7 статьясына үзгәрешләр кертү хакында" (2017 елның 29 декабрендәге үзгәрешләр белән) 19.12.2016 елдагы № 433-ФЗ Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Чернобыль АЭСындагы һәлакәт, "Маяк" җитештерү берләшмәсендәге авария нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарга һәм аларга тиңләштерелгән торак урыннарына мохтаҗ аерым категорияләрдәге затларга исәпкә кую һәм Дәүләт торак сертификатын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына, Татарстан Республикасы Әтнә районы Башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 08.06.2017 елдагы № 222 карары белән расланган түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1 нче кушымтаның 2.5 пунктының 5 пунктчасын төшереп калдырырга;

1.2. 1 нче кушымтаның 2.5 пунктының 11 пунктчасында "14 яшькә кадәр» сүзләреннән соң «14 яшькә кадәр; чит ил дәүләтенең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклыклар һәм аларны нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе» җөмләсен өстәргә;

1.3. 1 нче кушымтаның 2.5 пунктының 12 пунктчасын төшереп калдырырга;

1.4. 1 нче кушымтаның 2.5 пунктына түбәндәге эчтәлекле 14 пункт өстәргә:

“14) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар турында белешмәләр.»;

1.5. 1 нче кушымтаның 2.6 пункытның 2 пунктчасын төшереп калдырырга;

1.6. 1 нче кушымтаның 2.6 пунктының 3 пунктчасын төшереп калдырырга;

1.7. 1 нче кушымтаның 2.6 пунктын түбәндәге эчтәлекле 5 пунктчасы белән өстәргә:

“5) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар турында белешмәләр.».

2. Әлеге карарны Хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары М.Л. Халиковка йөкләргә.

Җитәкче А.Ф. Каюмов